ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт,

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.07.2015 Балык Бистәсе штп. № 188пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Имин шәһәр» техник чараларының аппарат-программа комплексы системаларын гамәлгә кертүгә һәм үстерүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эш төркеме турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 3 декабрендәге 2446-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү концепциясен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Имин шәһәр» техник чаралар аппарат-программа комплексы системаларын гамәлгә кертүгә һәм үстерүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2015 елның 20 мартындагы 455-р номерлы күрсәтмәсенә таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Имин шәһәр» техник чараларының аппарат-программа комплексы системаларын гамәлгә кертү һәм үстерүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эшче төркем булдырырга.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Имин шәһәр " техник чараларының аппарат-программа комплексы системаларын гамәлгә кертү һәм үстерүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эш төркеме турында нигезләмәне;

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Имин шәһәр» техник чараларының аппарат-программа комплексы системаларын гамәлгә кертү һәм үстерүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эш төркеме составын .

3. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы ,Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д. Ә. Низамовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 06 июлендәге 188 пи номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында “Имин шәһәр” техник чараларының аппарат-программа комплексы системаларын гамәлгә кертү һәм үстерүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эш төркеме турында нигезләмә**

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Имин шәһәр» техник чараларының аппарат-программа комплексы системаларын гамәлгә кертү һәм үстерүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба-ведомствоара эш төркеме) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Имин шәһәр» техник чараларнының аппарат - программа комплексын төзү һәм үстерү концепциясен эшләү өчен төзелгән координацион орган булып тора.

2.Ведомствоара эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3.Ведомствоара эш төркеменең төп бурычы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Имин шәһәр» техник чаралар комплексын төзү һәм үстерү концепциясен эшләү.

4. Күрсәтелгән бурычны хәл иткәндә ведомствоара эшче төркем билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, учреждениеләр, барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләр, галимнәр һәм экспертлар белән эш итә.

5. Ведомствоара эшче төркем түбәндәгеләргә хокуклы:

- билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан, учреждениеләрдән, барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләрдән ведомствоара эш төркеме компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча кирәкле материаллар соратып алырга;

ведомствоара эш төркеме компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча координация киңәшмәләрен һәм эш очрашуларын билгеләнгән тәртиптә оештырырга һәм уздырырга;

-фәнни-тикшеренү, мәгариф оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләр белгечләрен ведомствоара эш төркеме эшчәнлегенә билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә.

6. Ведомствоара эш төркеме составына рәис урынбасары, ике урынбасар, җаваплы секретарь, шулай ук Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары, ведомстволар, оешмалар, учреждениеләр, барлык милек

рәвешләрендәге предприятиеләр вәкилләреннән торган ведомствоара эш төркеменең башка әгъзалары керә.

7. Ведомствоара эш төркеме рәисе:

ведомствоара эш төркеме эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

- ведомствоара эш төркеменең утырышларын уздыру урынын һәм вакытын, шулай ук аларның көн тәртибен билгели;

ведомствоара эш төркеме эшчәнлеген оештыра һәм аның карарларын үтәүне тикшереп тора;

- ведомствоара эш төркеменең үз компетенциясенә керә торган аерым мәсьәләләрне карау тәртибен билгели.

8. Ведомствоара эш төркеме рәисенең вакытлыча булмавы чорында ведомствоара эш төркеменең эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Ведомствоара эшче төркем рәисе урынбасарларының берсе.

9.Ведомствоара эшче төркем утырышлары кирәк саен үткәрелә, ләкин кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла.

Ведомствоара эш төркеме утырышларын ведомствоара эш төркеме рәисе үткәрә.

Ведомствоара эшче төркем утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала.

Ведомствоара эш төркеме әгъзалары утырышларда алыштыру хокукыннан башка катнаша. Ведомствоара эшче төркем әгъзасы булмаган очракта, утырышта ул карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә тәкъдим итәргә хокуклы.

10.Ведомствоара эшче төркем карарлары утырышта катнашучы ведомствоара эш төркеме әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм утырышта рәислек итүче һәм ведомствоара эш төркеменең җаваплы секретаре тарафыннан имзаланучы беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

11.Ведомствоара эш төркеме эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты башкара.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 06 июлендәге 188 пи номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Имин шәһәр» техник чараларының аппарат-программа комплексы системаларын гамәлгә кертү һәм үстерүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эш төркеме составы**

| | |
|---|---|
| Хәбибуллин Р.Х. | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы, эш төркеме рәисе Татарстан |
| Ветёлкин В.И. | Республикасы буенча Федераль янгынга каршы хезмәтнең «128-ПЧ» федераль дәүләт казна учреждениесе башлыгы, эш төркеме рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Абдуллин Г.А. | «Таттелеком» ПАО Балык Бистәсе РУЭС башлыгы, эш төркеме рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Гребенщиков А.В | Федераль янгынга каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең «128-ПЧ» федераль дәүләт казна учреждениесе башлыгы ярдәмчесе, эшче төркемнең рәис урынбасары, җаваплы секретаре (килешү буенча) |
| Низамов Д.А. | Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары |
| Мостафин Н.Ф. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Ногманова И.М. | Балык Бистәсе муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча |
| Китаев М.Р. | «Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| Садиков И.М. | «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы |
| Мәннанов М.Г. | «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ башлыгы |
| Гатиятов Д.Х. | Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы |
| Баканин Е.А. | «Татавтодор» ААҖнең «Рыбнослободский» ДРСУ юл участогы башлыгы (килешү буенча) |
| Бариев Р.Г. | «Кама» җитештерү берләшмәсе рәисе (килешү буенча) |
| Киселёв А.В. | «Таттелеком» ПАО Балык Бистәсе РУЭС баш инженеры (килешү буенча) |
| Мишин А.А. | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсенең Алексеевск һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлекчәсе белгече (килешү буенча) |